Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк авылында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 21 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк авылында гражданнар җыены **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2020 елда, көндезге формада укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Бәйрәкәтамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Көрәш-Бүләк авылына кергәндә, юлны асфальт япма белән ремонтлау (асфальт булдыру, аны җәю, эшләр өчен килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә **http://pravo.tatarstan.ru** веб адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга һәм карар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда да урын алырга тиеш.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башлыгы Әгълиева З.М.